| СОВЕТ БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ КИНӘШЛӘР |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«08» июнь, 2020 ел Олы Подберезье авылы №9

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 октябрендәге 13 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.02.2020 елның 27 февралендәге 27-ФЗ номерлы Федераль законга, «Бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 307-ФЗ Федераль законга туры китерү максатында Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымтада каралганча үзгәрешләр кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 79 статьясындагы 3 өлешенең, 84 статьясындагы 5 өлешенең 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга.
3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://bpberez-kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Н.В. Кальчев

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге
Советының
08 июнь 9 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:
- авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә бизәү;
- җирлек территориясен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруда гражданнар һәм оешмаларның катнашу тәртибен тормышка ашыру;
- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту.»

2. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 5 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 20,21,22 пунктлар өстәргә:garantf1://86367.170181

20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үз белдегең белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү;

21) күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары, капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау тәртибе турында хәбәр итү;

22) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ туганда Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән кире һәм (яки) кире кайтарылмый торган нигездә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм очраклары исемлеген раслау.».

3. 6 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктында «яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тору чаралары» сүзләрен «хуҗаларсыз яшәүче хайваннар белән эш итү эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга.

4. 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 статья. Гражданнар җыены

1. Гражданнар җыены халык тарафыннан турыдан-туры җирле үзидарә гамәлгә ашырылу һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы рәвеше булып тора.

2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Торак пунктта бер үк вакытта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысы бергә булу мөмкинлеге булмаса, авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнар җыены

этаплап, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.

3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) торак пунктта күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

2) җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

3) авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасынын вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

4) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин;

5) әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирлек составына керүче торак пунктта;

4. Гражданнар җыены муниципаль берәмлек башлыгы яисә сайлау хокукына ия, кимендә 10 кеше булган торак пунктта яшәүчеләр төркеме инициативасы белән чакырыла ала.

5. Җыен үткәрү инициативасын хуплау йөзеннән җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия, торак пункт территориясендә даими яки нигездә яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин 25 тән дә ким була алмый.

6. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан чакырылучы гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнә.

7. Торак пунктта яшәүчеләр халык җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итәләр, муниципаль хокукый акт проекты һәм гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарылучы мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә танышалар.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.».

9. 30 статьяның 10 өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

10. 30 статьяның 12 өлешендә «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану турында» сүзләрен өстәргә.

11. 30 статьяны киләсе эчтәлектәге 12.1., 12.2. өлешләренә өстәргә;

«12.1. Үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән җирлек Советы депутатына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

кисәтү;

җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органында, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче, җирлек советында, Җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итеп, азат итү;

вәкаләтләре срогы тәмамланганчы ук вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

вәкаләтләре тәмамланганчы Җирлек советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүне тыю;

вәкаләтләр срогы тәмамланганчы вәкаләтләрне даими нигездә үтәүне тыю.

12.2. Җирлек Советы депутатына әлеге статьяның 12.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

12. 33 статьяның 1 өлешендәге 24 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

13. 43 статьяның 5 өлешендә « Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

14. 43 статьяны киләсе эчтәлектәге 5.1., 5.2.өлешләренә өстәргә:

«5.1. Үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән җирлек башлыгына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

кисәтү;

Җирлек Башлыгын, җирле үзидарәнең сайланулы органында, аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, җирлек советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итеп, азат итү;

вәкаләтләре срогы тәмамланганчы ук вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

вәкаләтләре тәмамланганчы Җирлек советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүне тыю;

вәкаләтләр срогы тәмамланганчы вәкаләтләрне даими нигездә үтәүне тыю.

5.2. Җирлек Башлыгына әлеге статьяның 5.1 өлешендә күрсәтелгә жаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарста Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

15. 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Башлыгы:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аш шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешм белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында җирлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез Идарәдә катнашырга, башк иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсе милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашырга;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәр берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, җирлекнең сайла комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау орган тарафыннан, Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) алдан хәбәрнамәсе белән, съездда (конференцияләрдә) яки башка иҗтимагый оешманың торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) катнашырга;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итәргә;

г) Җирлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә җирлекнең идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер) булган оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясендә җирлек мәнфәгатьләрен бушлай тәкъдим итәргә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы түгел. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә хокуклы түгел».

16. 45 статьяның 8 өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

17. 45 статьяны киләсе эчтәлектәге 8.1, 8.2. өлешләре белән тулыландырырга:

«8.1. Үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән авыл җирлеге урынбасарына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

кисәтү;

җирле үзидарәнең сайланулы органында, Җирлек советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазифа биләүдән мәхрүм итеп, Җирлек Башлыгы урынбасарын азат итү;

вәкаләтләре срогы тәмамланганчы ук вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

вәкаләтләре тәмамланганчы Җирлек советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүне тыю;

вәкаләтләр срогы тәмамланганчы вәкаләтләрне даими нигездә үтәүне тыю.

8.2. Җирлек Башлыгы урынбасарына әлеге статьяның 8.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

18. 45 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Җирлек Башлыгы урынбасары хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, җирлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез Идарәдә катнашырга, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашырга;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, җирлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) алдан хәбәрнамәсе белән, съездда (конференцияләрдә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) катнашырга;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итәргә;

г) Җирлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә җирлекнең идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә, гамәлгә

куючы (акционер) булган оешманың идарә итү органнарында һәм ревизи комиссиясендә җирлек мәнфәгатьләрен бушлай тәкъдим итәргә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүл эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы түгел. Шул ук вакытта укытучылы фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкар шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булс чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һә гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерацияс законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр як күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит и коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләр составына керергә хокуклы түгел».

19. «Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләре» 49 статьясында :

1 өлешнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«- Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә, үз белдеге белән төзелгә корылманы сүтү, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсә ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белә билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору, территориян планлаштыру документлары яисә федераль законнарда билгеләнгән капитал төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән тәңгәлләштеру турында карарлар кабул итә;

- күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары, капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау тәртибе турында хәбәр итә;

- күп фатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауда кичектергесез ихтыяҗ туганда Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән кире һәм (яки) кире кайтарылмый торган нигездә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм очраклары исемлеген раслый.».

1 өлешнең 4 пунктындагы 2 абзацында «кече һәм урта эшкуарлыкны үстеру өчен шартлар тудыра» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 өлешнең унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирлек территориясендә яшәүче хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген башкара;»;

3 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә алып барыла;»;

3 өлешнең 4 пунктында «Җирлектә вәкаләтле җирле үзидарә органнары башкара торган муниципаль контрольдән тыш» сүзләрен төшереп калдырырга;

20. 59 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә «Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыру өчен әлеге устав белән Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә торган чорга эш урынын (вазыйфаларны) саклау гарантияләнә һәм бер айга ике эш көненнән дә ким һәм

алты эш көненнән артык булмаска тиеш.».

21. 82 статьяның 1 өлешендәге 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль эчке бурыч алулар дигәндә, җирлек исеменнән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан заем акчаларын җирлек бюджетына җәлеп итү аңлашыла, алар буенча Россия Федерациясе валютасында белдерелгән заемчы буларак җирлекнең бурыч йөкләмәләре барлыкка килә.».

22. «Муниципаль финанс контроле» 85 статьясында:

1 өлешнең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләр һәм йөкләмәләр, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

2,3 өлештә ««бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.